**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**егерме сигезенче утырыш**

# КАРАРЫ

14 июнь 2019 ел **№ 176** Теләче авылы

Муниципаль контроль төрләре һәм аларны Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 13 номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» гы 2008 елның 26 декабрендәге 294 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына (И. Х. Хәмидуллин) йөкләргә:

2.1. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару буенча Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структура бүлекчәсен билгеләргә;

2.2. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы И.Ф. Зарипов

Теләче муниципаль
район Советының
2019 елның 14 июненнән 176 нчы номерлы
карарына кушымта

**Муниципаль контроль төрләре һәм аларны Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибе**

1. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибе (алга таба – Тәртибе) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»гы 2008 елның 26 декабрендәге 294 номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольнең ачыклыгын һәм үтемлелеген тәэмин итү максатларында эшләнгән һәм муниципаль контроль төрләре, аларны Теләче муниципаль районы территориясендә тормышка ашыруга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген формалаштыру һәм алып бару процедурасын билгели (алга таба - Исемлек.)

2. Исемлек Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан әлеге Тәртипкә кушымта белән билгеләнгән форма буенча төзелә һәм алып барыла.

3. Исемлеккә түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

1) Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре исеме;

2) муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының исеме, аларның урнашу урыны, телефоны;

3) муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итә торган Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структура бүлекчәләре яисә вазыйфаи затлары исеме, аларның урнашу урыны, телефоны;

4) муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында Теләче муниципаль районы муниципаль норматив-хокукый актының исеме һәм реквизитлары.

4. Исемлеккә үзгәрешләр кертү әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы 4 пунктчасында каралган муниципаль норматив- хокукый акт кабул ителгән (бастырып чыгарылган) көннән 10 көн эчендә яисә аңа үзгәрешләр кертелгән көннән гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны регламентлаучы һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләргә үзгәрешләр кертүче норматив- хокукый акт үз көченә кергән көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында тәкъдим җибәрә.. Муниципаль контрольне

гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы бетерелгән очракта, контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдим бетерелгән җирле үзидарә органы вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органы тарафыннан җибәрелә.

6. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы башкарма комитеты контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимне әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта карый һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдимнәр кергән көннән соң 10 көн эчендә контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертә.

7. Контроль төрләре исемлегенә кертелгән мәгълүмат һәркем өчен ачык. Контроль төрләре исемлеге Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

8. Исемлек Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Муниципаль контроль төрләре һәм аларны Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибенә

(форма)

**Муниципаль контроль төрләре һәм аларны Теләче муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырырга вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеге**

| № п/п | Муниципаль контроль төрләре исеме | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының исеме (урнашу урыны, телефоны) | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итә торган Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структура бүлекчәләре яисә вазыйфаи затлары исеме (аларның урнашу урыны, телефоны) | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында Теләче муниципаль районы муниципаль норматив- хокукый актының исеме һәм реквизитлары. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |